**Үпкәләүчән балалар**

Кешене башка кешеләр тарафыннан кире кагулары яисә бөтенләй аның белән саннашмаулары аркасында барлыкка килгән авыр кичерешне үпкә диеп аңлап була.
Үпкәләүчәнлек кешенең үз тормышын һәм якыннарының тормышын агулый торган сыйфат.
Үпкә дуслыкны җимерә, күренә һәм күренми торган бәхәсләрне китереп чыгара. Нәтиҗәдә кешене шәхес буларак җимерә.
Үпкә күренеш буларак мәктәпкәчә яшендә барлыкка килә. 3-4 яшендәге кечкенә балалар олыларның начар бәяләүләре аркасында борчылалар, үзләренә игътибар таләп итәләр, яшьтәшләре өстеннән әләклиләр. Тик бу үпкәләүләр ситуатив характерлы, һәр балага да хас, балалар аларны тиз оныталар
Беренче зурлар , ә аннан соң яшьтәшләре тарафыннан хөрмәт һәм үзен кабул итү мохтаҗлыгы 4-5 яшьлек балада барлыкка килә һәм үпкә феномен буларак тулысынча шушы вакыттан соң күренә башлый.
Үпкәнең барлыкка килү очраклары түбәндәге:
- баланы кабул итмәү, кирәгенчә игътибар бирмәү (мәсәлән, уйнарга чакырмау, теләгән ролен бирмәү);
-кирәген һәм теләгәнен бирмәү ( уенчык, бүләк, тәмле ризык бирмәү);
-башкалар тарафыннан хөрмәтләмәү( үртәү, начар сүзләр әйтү);
-мактамау, башкаларның уңышларын һәм өлгерлекләрен генә күрү, ә аңа игътибар бирмәү).
Тик шуны белергә кирәк, үпкәләүчән балалар мондый очракларда агрессия күрсәтмиләр (сугышмыйлар). Үпкәләүче үзенең тотышы белән “син гаепле, гафу үтен миннән” диеп тора. Ул сөйләшүдән туктый, демонстратив рәвештә борылып баса, үзенең “борчуларын” күрсәтә. Мондый очракларда барлыкка килгән үпкә хисенең сәбәбе ачык, нигезле.
Ә кайбер очракларда аны хөрмәт тә итәләр, кабул да итәләр, чакыралар да , ә ул сәбәпсезгә үпкәләп басып тора. Бу шәхесне җимерүче үпкәләүчәнлек сыйфаты. Андый балалар еш үпкәлиләр. Әйләнә - тирәдәге һәр кешедә үзләренә карата хөрмәтсезлекне, аның белән саннашмаулыкны эзлеле рәвештә күрәләр.
Үпкәләүчән балаларга бәяләү хас, алар һәрвакытта үзләрен яхшы бәяләүне көтәләр. Бер яктан караганда алар әйләнә - тирә кешеләренең үзләренә карата уңай мөнәсәбәтенә ореинтлашканнар, үзләренең тотышлары белән даими рәвештә аларны хөрмәт итүләрен, кабул итүләрен таләп итәләр. Икенче яктан карасаң, үпкәләүчән балалар уйлаулары буенча, кешеләр аларны дөрес бәяләмиләр, шуңа күрә, башкалар ягыннан начар бәяләрләр диеп фикерлиләр. Бәхәсле очракларда алар бәхәсне чишү юлын эзләмиләр, катнашучыларны бәяләүгә керешәләр. Үзен башкалар арасында яклау,калганнарның хатасын эзләү –мондый шөгыль аңа канәгатьлек бирә.